ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА МАМАДЫШ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ МАМАДЫШ
ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-31-55, факс 3-17-51, e-mail: Gorod.Mam@tatar.ru, www.mamadysh..tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**
№ 36 « 26 » март 2020 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә йорт хайваннарын урамда йөртү өчен билгеләнгән урыннарны билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 498 – ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең» 7 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советының 2018 елның 19 апрелендәге 2-24 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре» нең 7 нче бүлеге, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Башкарма комитеты турындагы Нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Башкарма комитеты
к а р а р б и р ә:

1. «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә йорт хайваннарын урамда йөртү өчен, тиешле элмә такталар куеп, түбәндәге территорияләрне билгеләргә:
— Нократ елгасының яр ныгыту дамбасы һәм Нократ Яр буе (Набережная Вятки) урамындагы шәхси сектор арасындагы территория;
— Чапаев урамының шәхси секторы һәм Ушма елгасының яр ныгыту дамбасы арасындагы территория;
— Мамадыш шәһәрен әйләнеп үтүче юл һәм Урау юл (Объездная)_ урамы арасындагы территория;
— Пузанка тавында чокыр буйлап утыртылган үсентеләр арасындагы территория.

2. Түбәндәге урыннарда йорт хайваннары белән йөрү тыела:
- балалар спорт мәйданчыкларында;
- парклар, скверлар, массакүләм ял итү урыннарында;
- балалар, белем бирү һәм дәвалау учреждениеләре территорияләрендә;
- мәдәният һәм сәнгать объектлары янындагы территорияләрдә;
- мәйданнарда, бульварларда;

- җәмәгать туклануы оешмаларында, кибетләрдә, хайваннар белән бергәләп йөрү өчен махсуслаштырылган объектлардан тыш. Әлеге пунктның гамәлдә булуы җитәкләп йөртүче (поводырь) этләргә кагылмый.

3. Йорт хайваннарын урамда йөртү аларның хуҗалары күзәтүе астында гына рөхсәт ителә.
4. Йорт хайваннары экскрементлары табигый ихтыяҗларны канәгатьләндергәннән соң әлеге хайваннарның хуҗалары тарафыннан җыештырылырга һәм каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен билгеләнгән чүп контейнерларына яки башка савытларга урнаштырылырга тиеш.
5. Әлеге карарда күрсәтелгән таләпләрне бозган өчен йорт хайваннары хуҗалары гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә административ җаваплылыкка тартыла.
6. Әлеге карарны районның «Нократ» («Вятка») газетасында, интернет мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru хокукый рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарыга (халыкка игълан итәргә).
7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р. М. Гарипов